**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 май № 339

г. Казань

Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир
кишәрлекләрен алу турында

«Сорочьи Горы – Шәле» автомобиль юлын төзү һәм реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII[1] бүлегендәге 49 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Питрәч муниципаль районында урнашкан, З.З.Галәветдинов милкендә булган 12,8445 гектар мәйданлы 16:33:170415:86 кадастр номерлы җир кишәрлеген (алга таба – җир кишәрлеге) автомобиль юлын урнаштыру өчен сатып алу юлы белән, урнаштыруның башка вариантлары булмаганда, алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

җир кишәрлегенең сатып алу бәясен билгеләүне һәм аның милекчесе белән тиешле килешүләр төзүне;

җир кишәрлегенең тиздән алыначагы турында милекчегә хәбәр итүне;

бу карарны дәүләт теркәвенә алуны һәм теркәү үткәрелү турында, аны теркәү датасын күрсәтеп, җир милекчесенә хәбәр итүне;

милекче җир кишәрлеген алу турындагы карар белән килешмәгән очракта, судка тиешле дәгъвалар кертүне;

сатып алынган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алу үткәрүне.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына җир кишәрлегенең сатып алу бәясен билгеләгәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетына җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкенә сатып алу чыгымнарын финанслау күләме һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\339.doc